ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2024 с.Старое Дрожжаное № 504

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмати-методика бүлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2024 елның 22 ноябрендәге под-1950/24 номерлы «Мәгариф эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик тәкъдимнәр турында» 2022 елның 29 мартындагы 583/22 номерлы боерыкка үзгәрешләр кертү хакында»гы боерыгы нигезендә Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31 мартындагы 169 номерлы карары (28.08.2024 № 361, 16.09.2024 № 382) белән расланган Мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ составындагы мәгълүмати-методик бүлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1 пунктның 2 бүлегендә** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль берәмлекләрнең мәгариф бүлекләре (идарәләре)

структурасындагы мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең нигез окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның атамасы | Аена база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка "бакалавр", "магистр" яки "дипломлы белгеч" квалификацияләрен биру белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 20246,0 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 20251,0 |
| | | | | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) урынбасары;<br><br>Муниципаль берәмлекләр | - | - | 20329,0<br><br>20405,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (начальнигы); | | | |

«Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы ведомство (тармак) бүләкләре» **бүлегенең 1 пунктына** түбәндәге эчтәлекле 1.12 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1.12. | «Яшьлек һәм Профессионализм» күкрәк билгесе. |

2. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигына (Хәлиуллов Г.Ф.) җирле хокукый актларны әлеге карарга туры китерергә.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.Ф. Заляловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.И. Мөхәммәтҗанов